КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 10 сентябрь

г.Казань

№ 823

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алучының балигъ булган гаилә әгъзаларының керемнәре булмау (бу Тәртипнең һәм шартларның 3.3 нче пунктында күрсәтелгән чорда 18 яшькә кадәрге инвалид баланы яки балачактан I төркем инвалидны карауны гамәлгә ашыручы эшләмәүче эшкә сәләтле затларга ай саен түләнә торган түләү билгеләнгән ата-аналардан (уллыкка алучылардан) яки опекуннардан (попечительләрдән) тыш);»;

түбәндәге эчтәлекле 3.71 нче пункт өстәргә:

«3.71. Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза биргән көнгә «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән

билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гаилә әгъзаларының керемнәре исәпкә алынмый. Әлеге керемнәргә бу Тәртипнең һәм шартларның 2.2 нче пунктындагы тугызынчы абзацы белән күздә тотылган керемнәр керә.»;

4.4 нче пунктта «, йә почта элемтәсе оешмасы аша» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 нче пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары 2020 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була;

бу карар (бу пункт белән үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

бу карарның 1 нче пунктындагы алтынчы абзацы 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин